| | | |
|---|---|---|
| ГЛАВА<br>ПОДЛЕСНО-<br>ШЕНТАЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>УРМАН АСТЫ ШОНТАЛАСЫ<br>АВЫЛ СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | с. Подлесная<br>Шентала | **КАРАР** |
| 02.12.2021 | | №6 |

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын**
**кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча**
**Алексеевск муниципаль районының**
**Урманасты Шонталысы авыл җирлегенең Урманасты Шонталысы**
**авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урманасты Шонталысы авыл җирлеге Уставы нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урманасты Шонталысы авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.
2. Алексеевск муниципаль районының Урманасты Шонталысы авыл җирлегенең Урманасты Шонталысы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 16 декабрендә график нигезендә билгеләргә (Кушымта).
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;
-юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу;
-бензогенераторны сатып алу;
- контейнерлар сатып алу;
- роторлы чапкычлы мотоблок сатып алу;
-тракторны карап тоту (тракторчыга түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу, запас частьләр сатып алу)
- су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал сатып алу);
- карны чистарту;

-Бөек Ватан сугышы һәйкәлен төзекләндерү;

ӘЙЕ ЮК».

4. Әлеге карарны Урманасты Шонталысы авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урманасты Шонталысы авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Урманасты Шонталысы**
**авыл җирлеге башлыгы** **А.А.Җиһаншин**

Кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының**
**Урманасты Шонталысы авыл җирлегенең Урманасты Шонталысы авылында**
**үзара салым кертү мәсьәләсе буенча**
**гражданнар җыенын этаплап уздыру**
**ГРАФИГЫ**

| **Тәртип саны** | **Үткәрү датасы** | **Үткәрү вакыты** | **Үткәрү урыны** | **Урамнарның исеме** |
|---|---|---|---|---|
| 1. | 16.12.2021 | 9.00 | Урманасты Шонталысы АМЙ, Г.Тукай ур., 42 й. | Г.Тукай ур., Биләр ур. |
| 2. | 16.12.2021 | 11.00 | Урманасты Шонталысы АМЙ, Г.Тукай ур., 42 й. | Г.Исхакый ур., М.Җәлил ур. |
| 3. | 16.12.2021 | 13.00 | Урманасты Шонталысы АМЙ, Г.Тукай ур., 42 й. | К. Маркс ур., Гагарин ур. |